## Миндубаева Энҗе Кыяметдин кызы(1972 елда туган).
### Мәктәп директоры

Әле кайчак уйланып утырам да, пионер, комсомол оешмаларының уңай яклары күп булган инде ул. Бездә, балаларда, бердәмлек, татулык хисе тәрбияли иде, кайда да беренче булырга омтылып үстек без. Мәктәп — бер дружина, һәр класс — бер отряд иде. Отрядлар арасында һәрчак ярыш рухы булды, бөтен максатыбыз — укуда, җәмәгать эшләрендә алдынгылардан булу. Укулары аксаган иптәшләрне «тарту», ягъни дәрестән соң калып шөгыльләнү дигән нәрсә бар иде. Кыскасы, һәрчак бер-беребезгә ярдәм иттек, бер гаилә кебек тату булып үстек.

Урманасты Шынталысы